РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Простинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423553, Нижнекамский район,
с. Прости, ул. Школьная, 8

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Прости авыл җирлеге
Советы

423553, Түбән Кама районы,
Прости авылы, Мәктәп урамы, 8

тел./факс (8555) 44-98-35, электронный адрес: Prostinskoe.sp@tatar.ru,
сайт: www. prostinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

14.11.2023 ел — № 19

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 23 июлендәге 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендә 78 статьясының 1 пунктындагы икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Прости авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2018 елның 23 июлендәге 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2.2 пунктында:

«объектлар белән» сүзләрен «һәм (яки) объектлар белән» сүзләренә алыштырырга;

«объектка туры килгән җир кишәрлегенә хокукка өлеше» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килгән җир кишәрлеге өлешләре» сүзләренә алыштырырга;

«һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яки) объектларга» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Д.Ә. Бәдәртинов